КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 27 март г.Казань № 174

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 20 декабрь, 1172 нче карары белән расланган 2025 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген раслау турында» 2024 ел, 20 декабрь, 1172 нче карары белән расланган 2025 елга Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең 2023 – 2025 елларга Татарстан Республикасы инвестиция меморандумында билгеләнгән өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлектә:

3 пунктта:

8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) «Синтез һәм эшкәртү продукциясе җитештерү кластеры» («Ашлыкны тирәнтен 500 000 тонна/г куәтле эшкәртү», «Метионин җитештерү») (В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» ГАҖ, Түбән Кама муниципаль районы);»;

түбәндәге эчтәлекле 9 – 11 пунктчалар өстәргә:

«9) «Галобутил каучукларын җитештерүне елга 200 мең тоннага кадәр техник яктан яңадан коралландыру» («Түбән Кама нефтехим» ГАҖ, Түбән Кама шәһәре);

10) «Линеяле альфа-олефиннарны җитештерүне модернизацияләү» («Түбән Кама Нефтехим» ГАҖ, Түбән Кама шәһәре);

11) «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә түбән басым полиэтиленыннан һәм полипропиленнан гофрирланган торбалар җитештерү» («Агротехнологияләр» ҖЧҖ, Лаеш муниципаль районы).»;

8 пунктта түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча өстәргә:

«10) «220 кВ Бигеш - Чистай - 220 ЮВЛ төзелеше» («Сетевая компания» АҖ, Алексеевск, Әлки, Аксубай, Яңа Чишмә, Нурлат, Спас, Чистай муниципаль районнары).»;

9 пунктка түбәндәге эчтәлекле 12 - 14 пунктчалар өстәргә:

«12) «Әлмәт - Түбән Новгород» магистраль нефть продуктлары үткәргеченең, дизель ягулыгын бер елга 13,3 млн. тонна күләмдә суырту өчен 500 мм диаметрлы үткәрү сәләтен киңәйтү. «Әлмәт» баш суырту станциясе. Реконструкция» («Транснефть - Прикамье» АҖ, Әлмәт муниципаль районы);

«13) «Әлмәт - Түбән Новгород» магистраль нефть продуктлары үткәргеченең, дизель ягулыгын бер елга 13,3 млн. тонна күләмдә суырту өчен 500 мм диаметрлы үткәрү сәләтен киңәйтү. «Ковали-1» продукт суырту станциясе. Техник яктан яңадан коралландыру («Транснефть - Прикамье» АҖ, Әлмәт муниципаль районы);

14) «Әлмәт - Түбән Новгород» магистраль нефть продуктлары үткәргеченең, дизель ягулыгын бер елга 13,3 млн. тонна күләмдә суырту өчен 500 мм диаметрлы үткәрү сәләтен киңәйтү. «Михайловка-1» продукт суырту станциясе. Техник яктан яңадан коралландыру («Транснефть - Прикамье» АҖ, Әлмәт муниципаль районы).»;

10 пунктка түбәндәге эчтәлекле 30 - 33 пунктчалар өстәргә:

«30) «Зур Идел» мега-паркы» («ЯДРАН-СТРОЙ» ҖЧҖ, Казан шәһәре);

31) «Казан шәһәренең Вахитов районында премиаль дәрәҗәсендәге кунакханә комплексы» («АМ Групп» ҖЧҖ , Казан шәһәре);

32) «Түбән Кама шәһәрендә логистик порт хабы булдыру» («ТЭМ-ПО» Чаллы торба заводы» АҖ, Түбән Кама шәһәре);

33) «Җиһазлар базасы» индустриаль паркы» («ТРИО ГРУПП» идарәче компаниясе» ҖЧҖ, Чаллы шәһәре).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин